**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге составына керүче “Татарстан” совхозы поселогы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

26 ноябрь, 2021 ел

№ 1

– «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 26 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2021 елда яшәү урыны буенча Кнәз авыл җирлеге “Татарстан” совхозы поселогы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- "Татарстан" совхозы торак пунктында коймалар әзерләү һәм урнаштыру;
-"Татарстан" совхозы торак пунктында яктырткычлар сатып алу, урам яктырткычларын монтажлау һәм урнаштыру;
- "Татарстан" совхозы торак пунктында юлларны ремонтлау;
- "Татарстан" совхозы торак пунктында М.Садовая урамын яшелләндерү һәм газон урнаштыру;
- "Татарстан" совхозы торак пунктында балалар мәйданчыгы урнаштыру (сатып алу һәм урнаштыру);
- "Татарстан" совхозы торак пунктында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру;
- "Татарстан" совхозы торак пунктында М.Садовая урамы буенча юл билгеләре кую;
- "Татарстан" совхозы торак пунктында видеокүзәтү урнаштыру;
- "Татарстан" совхозы торак пунктында территорияне чистарту һәм төзекләндерү (махсус техника хезмәте, грунт ташу);
- "Татарстан" совхозы торак пунктында зират территориясен төзекләндерү;
- "Татарстан" совхозы торак пунктында футбол кырының ясалма катламын урнаштыру.

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы **1989** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **1692** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **1646** кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы **46** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге "Татарстан" совхозы поселогы гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныйрга.

2. «2021 елда яшәү урыны буенча Кнәз авыл җирлеге "Татарстан" совхозы поселогы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- "Татарстан" совхозы торак пунктында коймалар әзерләү һәм урнаштыру;
-"Татарстан" совхозы торак пунктында яктырткычлар сатып алу, урам яктырткычларын монтажлау һәм урнаштыру;
- "Татарстан" совхозы торак пунктында юлларны ремонтлау;
- "Татарстан" совхозы торак пунктында М.Садовая урамын яшелләндерү һәм газон урнаштыру;
- "Татарстан" совхозы торак пунктында балалар мәйданчыгы урнаштыру (сатып алу һәм урнаштыру);
- "Татарстан" совхозы торак пунктында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру;
- "Татарстан" совхозы торак пунктында М.Садовая урамы буенча юл билгеләре кую;
- "Татарстан" совхозы торак пунктында видеокүзәтү урнаштыру;
- "Татарстан" совхозы торак пунктында территорияне чистарту һәм төзекләндерү (махсус техника хезмәте, грунт ташу);
- "Татарстан" совхозы торак пунктында зират территориясен төзекләндерү;
- "Татарстан" совхозы торак пунктында футбол кырының ясалма катламын урнаштыру.

3. Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге "Татарстан" совхозы поселогы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге "Татарстан" совхозы поселогы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кнәз авыл җирлеге Башлыгы

Ф.М.Камалов